**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"17" ноябрь 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылы территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алмаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Кече Әтнә торак пунктының җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

3) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Кече Әтнә торак пункты урамнары территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үләннәр чабу, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан, чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

4) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны карап тоту һәм төзекләндерү (үләннәр чабу, агачларны, куакларны, үсентеләрне кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

3. 2024 елга гражданнар җыены тарафыннан билгеләнгән гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 27 000 сум акчаны спорт мәйданчыгы төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау, материаллар сатып алу,эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы :

1)торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кече Әтнә торак пункты урам юлларын ремонтлау һәм ябу (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2024 елга гражданнар җыены тарафыннан билгеләнгән Кече Әтнә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 10 000 сум акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:
Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Кече Әтнә торак пунктының җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)) - **мәсьәләсен кабул итәргә**.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе С.Н.Порфирьев